**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«___» ________ 2025 ел Яр Чаллы ш. № _______

Халык тыңлаулары нәтиҗләре турында
бәяләмәне гамәлдән чыгару хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясы, район прокурорының шәһәр төзелеше законнарын бозуларны бетерү турында тәкъдиме нигезендә, проектны эшләп бетерүгә җибәрүгә бәйле рәвештә,

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2024 елның 02 октябрендәге 1, 2, 3, 4, 5, 6 номерлы халык тыңлаулары беркетмәләре буенча 2024 елның 02 октябрендәге Кече Шилнә авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча халык тыңлаулары нәтиҗәләре турында бәяләмәне гамәлдән чыгарырга.
2. Кече Шилнә авыл җирлегенең генераль планы проектын, тәкъдимнәрне һәм кисәтүләрне исәпкә алып, эшләп бетерергә җибәрергә.
3. Әлеге карарны районның рәсми сайтында урнаштырырга һәм «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р. Хәбибуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе К.Р. Нәҗмиев